ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**26.05.2026**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№1858**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 05 мартындагы 477 номерлы карары белән расланган, «Зеленодольск муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Зеленодольск муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш системасын камилләштерү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 05 мартындагы 477 номерлы карары белән расланган, «Зеленодольск муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасына, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 02 июлендәге 1766 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләре белән түбәндәге үзгәрешләрне керртергә:

1.1. «Зеленодольск муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау» бүлегенең 1.2.1 пунктындагы «муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. «Зеленодольск муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау» бүлегенең 1.2.6 пунктындагы «һәм күрсәтелгән вазыйфаларны биләүче затлар белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. «Зеленодольск муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау» бүлегенең 1.6 пункты үз көчен югалткан дип танырга.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин